ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
24 сентября 2020 года

**Статья 1**

Внести в Бюджетный кодекс Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II часть), № 10 (I часть), № 12 (IV часть); 2006, № 6 (I часть), № 12 (I часть); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III часть), № 10 (I часть); 2009, № 7 – 8 (I часть), № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть), № 12 (I часть); 2011, № 8 (I часть), № 11 (I часть), № 11 (II часть); 2012, № 11 (I часть); 2013, № 7, № 10, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 12 (III часть); 2015, № 7 (I часть), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III часть), № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 76 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 78 (часть I); 2019, № 2 (часть I), № 19 (часть I), № 79 (часть I); 2020, № 51 (часть I), № 57 (часть I) следующие изменения:

1) статьи 17 и 18 признать утратившими силу;

2) абзац первый пункта 10 статьи $44^6$ после слов «муниципальными образованиями» дополнить словами «, за исключением субвенций, источником финансового обеспечения которых являются межбюджетные трансферты за счет резервного фонда Правительства Российской Федерации, а также за счет резервного фонда Кабинета Министров Республики Татарстан,»;

3) в абзаце втором пункта 4 статьи $47^1$ слова «Главные администраторы средств бюджета Республики Татарстан, главные администраторы средств местного бюджета» заменить словами «Главные администраторы бюджетных средств»;

4) в пункте 5 статьи $52^1$ слова «Проект бюджетного прогноза (проект изменений бюджетного прогноза)» заменить словами «Бюджетный прогноз (проект бюджетного прогноза, проект изменений бюджетного прогноза)»;

5) в статье $53^1$:

а) в пункте 1 слова «в условиях действующего на момент» заменить словами «, действующего на день», после слов «в Государственный Совет Республики Татарстан» дополнить словами «, а также принятого на указанную дату и вступающего в силу в очередном финансовом году и плановом периоде», слова «, а также законодательства» заменить словами «и законодательства»;

б) пункт 2 изложить в следующей редакции:

«2. Положения законов Республики Татарстан, приводящих к изменению общего объема доходов бюджета Республики Татарстан и принятых после внесения проекта закона о бюджете Республики Татарстан на рассмотрение в Государственный Совет Республики Татарстан, учитываются в очередном финансовом году при внесении изменений в бюджет Республики Татарстан на текущий финансовый год и плановый период в части показателей текущего финансового года.»;

6) абзац третий пункта 3 статьи 77 после слов «распорядителей (получателей) бюджетных средств» дополнить словами «, централизацией закупок товаров, работ, услуг для обеспечения государственных (муниципальных) нужд в соответствии с частью 3 статьи 26 Федерального закона от 5 апреля 2013 года № 44-ФЗ «О контрактной системе в сфере закупок товаров, работ, услуг для обеспечения государственных и муниципальных нужд»;

7) абзац второй пункта 1 статьи $80^2$ дополнить словами «или иным лицом, уполномоченным действовать в установленном законодательством Российской Федерации порядке от имени этого органа»;

8) в пункте 2 статьи 93 слова «соответственно в целях предоставления субсидий, субвенций, иных межбюджетных трансфертов, имеющих целевое назначение» заменить словами «, соответствующих целям предоставления указанных средств»;

9) пункт 3 статьи $97^2$ дополнить словами «в установленные Министерством финансов Российской Федерации сроки».

**Статья 2**

Признать утратившими силу:

1) пункт 8 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 27 июня 2005 года № 78-ЗРТ «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан и Закон Республики Татарстан «О местном самоуправлении в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2005, № 6 (II часть);

2) пункт 2 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 22 июня 2006 года № 46-ЗРТ «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2006, № 6 (I часть); 2007, № 8;

2008, № 8 (III часть); 2013, № 10; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 76 (часть I);

3) пункты 9 и 10 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 2 августа 2007 года № 38-ЗРТ «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2007, № 8; 2009, № 1, № 7 – 8 (I часть); 2010, № 7 (II часть); 2012, № 11 (I часть); 2013, № 7, № 10; 2014, № 12 (III часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 76 (часть I);

4) пункт 1 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 16 октября 2013 года № 79-ЗРТ «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан и отдельные законодательные акты Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 10; 2014, № 11 (I часть); 2016, № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2018, № 78 (часть I);

5) пункт 4 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 18 декабря 2014 года № 127-ЗРТ «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан и Закон Республики Татарстан «О наделении органов местного самоуправления муниципальных районов государственными полномочиями Республики Татарстан по расчету и предоставлению дотаций поселениям из регионального фонда финансовой поддержки поселений» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 12 (III часть);

6) Закон Республики Татарстан от 25 сентября 2015 года № 64-ЗРТ «О внесении изменения в статью 17 Бюджетного кодекса Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2015, № 8 – 9).

**Статья 3**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования, за исключением положений, для которых настоящей статьей установлены иные сроки вступления их в силу.

2. Пункты 1, 2 и 5 статьи 1 и статья 2 настоящего Закона вступают в силу с 1 января 2021 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
28 сентября 2020 года
№ 61-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 24 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 17 һәм 18 статьяларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

2) $44^6$ статьяның 10 пунктындагы беренче абзацында «субвенцияләрне» сүзеннән соң «, финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды исәбеннән, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды исәбеннән бюджетара трансфертлар булган субвенцияләрдән тыш,» сүзләрен өстәргә;

3) $47^1$ статьяның 4 пунктындагы икенче абзацында «Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының баш администраторлары, җирле бюджет акчаларының баш администраторлары» сүзләрен «бюджет акчаларының баш администраторлары» сүзләренә алмаштырырга;

4) $52^1$ статьяның 5 пунктында «бюджет фаразы проекты (бюджет фаразына үзгәрешләр проекты)» сүзләрен «бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр проекты)» сүзләренә алмаштырырга;

5) $53^1$ статьяда:

а) 1 пунктта «вакытка гамәлдә булган» сүзләрен «көнгә гамәлдә булган» сүзләренә алмаштырырга, «шартларында» сүзен төшереп калдырырга, «гамәлдә булган» сүзләреннән соң «, шулай ук күрсәтелгән датага кабул ителгән һәм чираттагы финанс елында һәм план чорында гамәлгә керәчәк» сүзләренә алмаштырырга, «, шулай ук» сүзләрен «һәм» сүзенә алмаштырырга;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты турында закон проекты Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелгәннән соң кабул ителгән Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләре чираттагы финанс елында агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетына агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә үзгәрешләр керткәндә исәпкә алына.»;

6) 77 статьяның 3 пунктындагы өченче абзацында «үзгәртүгә» сүзеннән соң «, «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясындагы 3 өлеше нигезендә дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны үзәкләштерүгә» сүзләрен өстәргә;

7) $80^2$ статьяның 1 пунктындагы икенче абзацында «җитәкчесе» сүзеннән соң «яисә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шул орган исеменнән эш итәргә вәкаләтле башка зат» сүзләрен өстәргә;

8) 93 статьяның 2 пунктында «максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында тиешенчә» сүзләрен «күрсәтелгән акчаларны бирү максатларына туры килә торган» сүзләренә алмаштырырга;

9) $97^2$ статьяның 3 пунктында «хисабын» сүзеннән соң «Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән срокларда» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 27 июнендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 8 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 6 (II өлеш);

2) «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2006 елның 22 июнендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма

басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 8; 2008, № 8 (III өлеш); 2013, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 76 (I өлеш);

3) «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 2 августындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 9 һәм 10 пунктларын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 8; 2009, № 1, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10; 2014, № 12 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 76 (I өлеш);

4) «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 16 октябрендәге 79-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 10; 2014, № 11 (I өлеш); 2016, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 78 (I өлеш);

5) «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан җирлекләргә дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 18 декабрендәге 127-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 4 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (III өлеш);

6) «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 17 статьясына үзгәреш кертү турында» 2015 елның 25 сентябрендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 8 – 9).

**3 статья**

1. Әлеге Закон, үз көчләренә керүенең әлеге статьяда башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1, 2 һәм 5 пунктлары һәм 2 статьясы 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 28 сентябрь
№ 61-ТРЗ